ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 577-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.А. Ратникова, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 577-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2564-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.А. Ратникова,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында «дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычлары, хокуклары һәм вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен дәүләт органының административ регламенты, дәүләт органындагы структур бүлекчәнең бурычлары һәм функцияләре һәм дәүләт хезмәтенең шушы органда биләнүче вазыйфаның функциональ үзенчәлекләре нигезендә җаваплылыгы» сүзләрен «вазыйфаи бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 30 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктта «башка дәүләт органына» сүзләрен «яллаучы тәкъдиме белән шул ук дәүләт органында йә башка дәүләт органында башка вазыйфага» сүзләренә алмаштырырга;

б) $9^1$ пунктта «хезмәт урынына» сүзләрен «дәүләт хезмәте узу урынына» сүзләренә алмаштырырга;

в) $9^2$ пунктта «яңа хезмәт урынында» сүзләрен «дәүләт хезмәте узуның яңа урынында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 39 статьяның 4 өлешендә «дәүләт хезмәтенең яңа урынына» сүзләрен «дәүләт хезмәте узуның яңа урынына» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Законопроекты «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3 номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нормаларын федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

2024 елның 24 июлендә «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 апрелендәге 87-ФЗ номерлы Федераль закон гамәлгә керә аның нигезендә дәүләт граждан хезмәте турындагы федераль законнарның аерым нигезләмәләре төгәлләштерелә.

Әлеге Федераль закон нигезендә закон проектында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламенты эчтәлегенә таләпләр төгәлләштерелә (дәүләт хезмәткәренең хокуклары һәм аның вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен дәүләт органының административ регламенты, дәүләт органындагы структур бүлекчәнең бурычлары һәм функцияләре һәм дәүләт хезмәтенең шушы органда биләнүче вазыйфаның функциональ үзенчәлекләре нигезендәге җаваплылыгы вазыйфаи регламенттан төшереп калдырыла), шулай ук терминологик характердагы үзгәрешләр кертелә. «Хезмәт урыны» төшенчәсе «граждан хезмәте узу урыны» төшенчәсенә алмаштырыла.

---

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен башка органга күчергәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һәм аның гаилә әгъзаларының башка җирлеккә күчүгә бәйле чыгымнарын каплау тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 20 гыйнварындагы 14 номерлы карарына, шулай ук «Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органына ротация тәртибендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә торак урын яллауга чыгымнарны каплау кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 4 июнендәге 373 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чараларын бүлеп бирүне таләп итми.